**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Кызыл Бакча авылында 2024 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**17.11.2023 ел** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кызыл Бакча авылында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Кызыл Бакча торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I һәм II төркем инвалидларыннан, өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшьтән өлкәнрәкләр), җирлек территориясендә ел дәвамында яшәмәүче гражданнар, авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан, РФ Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 21.09.2022 ел, № 647 указы буенча мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү:

1) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кызыл Бакча торак пунктында Кызыл Бакча зират территориясенең коймаларын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);

2) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кызыл Бакча торак пункты зираты территориясен төзекләндерү (үлән чабу, йоклау һәм агачларны тамырыннан йолкып алу, чүп җыю һәм чыгару);

3) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кызыл Бакча торак пунктында Кызыл Бакча торак пунктына керү юлларын төзекләндерү (ташу, таш салу, вак таш салу, килешү буенча эш өчен түләү);

4) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кызыл Бакча торак пунктында балалар уен мәйданчыгына койма кую (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү).

3. Сарман муниципаль районының Кызыл Бакча авылы мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар Җыенының нәтиҗәләрен халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга (http://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы»
«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
МБ башлыгы Р.Ә. Каримов